**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

________________________ №______________________

г. Казань

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашулары өчен махсус билгеләнгән урыннар турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 24 июнендәге «Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетларуздыру буенча вәкаләтле орган турында» 436 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алып, боерам:

1.Түбәндәге кушымталарны расларга:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашулары өчен махсус билгеләнгән урыннар исемлеге;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашулар уздырулары өчен бүлмәләр бирү тәртибе.

2. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә әлеге боерыкны “Татарстан Республикасының рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары М.М.Ибәтовка йөкләргә.

Татарстан

Республикасы

Юстиция министрлыгының
__________№______

боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашулары өчен махсус билгеләнгән урыннар исемлеге

| № п/п | Оешмаларның исемнәре | Адрес | Бүлмә аталышы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Казан шәһәре Мәскәү районы халкының мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | Казан шәһ., Гагарин ур., 46 йорт | конференц-зал |
| 2 | «Чаллы шәһәре халкының мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | Чаллы шәһ., Сөембикә ур., 47 йорт | актлар залы |
| 3 | «Чаллы шәһәре» шәһәр округындагы «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном учреждениесе | Чаллы шәһ., Грин ур., 9 йорт | конференц-зал |
| 4 | «Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм халыкка социаль ярдәм күрсәтү министрлыгының Түбән Кама муниципаль районындагы «Милосердие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном учреждениесе | Түбән Кама шәһ., Кайманов ур., 16а йорт | актлар залы |
| 5 | «Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм халыкка социаль ярдәм күрсәтү министрлыгының Әлмәт муниципаль районындагы «Опека» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт | Әлмәт шәһ., К. Цеткин ур., 54А йорт | актлар залы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | автоном учреждениесе | | |
| 6 | «Әлмәт шәһәре халкының мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | Әлмәт шәһ., Герцен ур., 86А йорт | актлар залы |
| 7 | «Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм халыкка социаль ярдәм күрсәтү министрлыгының Алабуга муниципаль районындагы «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном учреждениесе | Алабуга шәһ., Городищенская ур., 4 йорт | конференц-зал |

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының
__________№________________
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашулары өчен махсус билгеләнгән бүлмәләрне бирү тәртибе

1. Әлеге тәртип «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының (алга таба – депутатлар) сайлаучылар белән очрашулары өчен бүлмәләр бирү процедурасын билгели.

2. Депутатларның сайлаучылар белән халык белән чара формасында очрашулары Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, халык йөрешләре һәм пикетлар турындагы законнары нигезендә уздырыла.

3. Депутатларның халык белән очрашулары өчен исемлекләре Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан расланган бүлмәләр (алга таба – бүлмәләр) бирелә.

4. Бүлмәләр депутатларга түләүсез нигездә бирелә.

5. Сайлаучылар белән очрашуга (алга таба – чарага) биш эш көненнән дә кимрәк вакыт калганчы депутат чараны уздыру турында бүлмә аның карамагында булган оешма җитәкчесенә язма гариза җибәрә. Гаризада чараның башлану һәм тәмамлану көне һәм сәгатьләре, чарада катнашучыларның фараз ителгән саны, чараны уздыру өчен җаваплы затның исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, элемтә өчен телефоны, шулай ук бүлмә бирелү турында  депутатка хәбәр итү алымы (илтеп тапшыру юлы белән, почта аша, телеграмма белән, факс элемтәсе аша, электрон почта аша, электрон документлар әйләнеше юлы белән) мәгълүмат бирү ысулы күрсәтелә.

Гариза оешма җитәкчесенә мөмкин булган теләсә-кайсы ысул белән җибәрелә (илтеп тапшыру юлы белән, почта аша, телеграмма белән, факс элемтәсе аша, электрон почта аша, электрон документлар әйләнеше юлы белән).

6. Бүлмә түбәндәге шартлар үтәлгән очракта бирелә:

чараның башлану вакыты агымдагы көннең җирле вакыт белән 07.00 сәгатеннән иртәрәк, төгәлләнү вакыты 22.00 сәгатьтән соңрак булмаган вакытка билгеләнә;

чарада катнашучылар саны бүлмәнең чик тулылыгының түбәндәге нормаларыннан чыкмый:

1) чара уздырылу урынында стационар тамашачылар урыннары белән җиһазландырылган бүлмәнең чик тулылыгы – стационар тамашачылар урыннары саныннан артык түгел;

2) чара уздырылу урынында стационар тамашачылар урыннары белән җиһазландырылмаган бүлмәнең чик тулылыгы – 1 кв.метрга 1 кешедән артык түгел яки бинаның (корылманың) техник паспорты нигезендә.

7. Гариза оешмага кергән көнендә, оешмага керә торган корреспонденцияне теркәү тәртибендә теркәлә.

8. Теркәлгән гариза кергән көнендә оешма җитәкчесенә яки аның вазыйфаларын башкаручыга ( алга таба – оешма җитәкчесе) тапшырыла.

Оешма җитәкчесе гаризаны кергән көнендә карый, гаризада күрсәтелгән көнгә һәм вакытка бүлмәне бирү турында акт (боерык, карар) чыгара (әлеге Тәртипнең 9 пунктында каралган очраклардан тыш) һәм чараны уздыру өчен бүлмә бирүне тәэмин итүгә җаваплы затны билгели. Әлеге акт имзаланганнан соң бер эш көне эчендә депутатка һәм Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының бинаның урнашу урыны буенча территориаль органына юллана.

Оешмага 14 сәгатьтән соң кергән гариза гариза кергән көннән соң килә торган эш көне тәмамланганчыга кадәрге вакыт эчендә карала.

9. Оешма җитәкчесе әлеге Тәртипнең 8 пунктында каралган вакытлар эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән депутатка түбәндәге очракларда чараны башка вакытта уздыру турында сәбәпләре, көнкрет көне һәм сәгате күрсәтелгән тәкъдимне юллый:

бинаның техник торышы канәгатьләнерлек булмаган, бинаның яки корылманың ишелеп төшү куркынычы булган яки чарада катнашучыларның иминлегенә башка төр куркыныч янаган очракта, әгәр дә бинаны гаризада күрсәтелгән көнгә һәм вакытка кадәр чараны уздыру өчен канәгатьләнерлек торышка китерү мөмкин булмаса;

әгәр дә чара уздыру өчен каралган бүлмә гаризада күрсәтелгән көн һәм вакытка башка депутатка (депутатларга) бирелгән булса;

әгәр дә бүлмәдә гариза кергәнчегә кадәр оешма җитәкчесе акты (боерыгы, карары) нигезендә башка чара уздыру планлаштырылган булса.

Әгәр дә чараны уздыру өчен гаризада күрсәтелгән шартлар әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган шартларга туры килмәсә, оешма җитәкчесе депутатка әлеге Тәртипнең 8 пунктында каралган вакытлар эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән чараны гаризада күрсәтелгән вакытта тиешле шартларны үтәп башкару турында, ә әлеге пунктның икенче, өченче һәм дүртенче абзацларында каралган очракларда, конкрет көн һәм вакытны күрсәтеп, башка вакытта уздыру турында тәкъдим юллый.

Чараны оештыру өчен депутатка оешма җитәкчесе тарафыннан тәкъдим ителгән вакыт әлеге пунктта чараны уздыруга каршылык тудыручы шартлар буларак каралган хәлләрне бетерүдән (туктатудан) соң 1 сәгатьтән дә соңрак булырга тиеш түгел. Күрсәтелгән хәлләрне 21.00 сәгатьтән дә алдарак бетерү (туктату) мөмкин булмаган очракта оешма җитәкчесе тарафыннан тәкъдим ителә торган вакыт чараны уздыруга каршылык тудыра торган хәлләр бетерелгән

(туктатылган) көннән соң килә торган көннең 07.00 сәгатеннән дә соңрак булырга тиеш түгел.

10. Депутат чараны уздыруга ике көннән дә кимрәк вакыт калганчы оешма җитәкчесенә чараны әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә тәкъдим ителгән датада һәм (яки) вакытта уздыруга ризалыгы (риза түгеллеге) турында әлеге Тәртипнең 5 пунктында каралган ысулларның берсе аша хәбәр итә.